


# «Сәләт» җәе: әйдә, безнең белән!

**Җәй – иң күңелле вакыт. Чөнки мәктәп укучыларының да, студентларның да җәйге каникуллары чоры. Инстаграм челтәрендә башкаларның матур фотоларына сокланып, вакытыңны бушка уздырганчы, син дә җәеңне алдан планлаштырып куй! Сәләтле балалар һәм яшьләр «Сәләт» берләшмәсе сиңа күңелле дә, файдалы да җәй тәкъдим итә!**

**ИГОРЬ СМИРНОВ,**
**«Сәләт» клубы президенты:**

– «Сәләт» җәйге аланнарының үзенчәлеге шунда: биредә сез ял итеп кенә калмыйча, файдалы белемнәр дә туплый аласыз. Бүген инде минем өчен «Сәләт» җәй генә түгел, ел әйләнәсе шушы сихри дөньяда кайныйм. «Сәләт» үсә, үзгәрә. Хәзер аның клублары Татарстан мәктәпләре базаларында гына түгел, хәтта Самарада да бар! Җәй исә – «Сәләт»нең кульминацион ноктасы булып тора. Җәен һәр сәлкеш үзенә көч туплый.

Татарстанда, традициягә кергәнчә, безнең аланнар Лаеш районындагы «Звездный» ял һәм сәламәтләндерү базасында, Алексеевскидагы «Фәнсар» фән һәм мәгариф үзәгендә үтә. Азнакай, Буа, Бөгелмә, Спас, Биектау районнарында, Яр Чаллы шәһәрендә дә профильле сменалар гөрләп эшли.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән төзелгән, 2015 елның июлендә рәсми рәвештә ачылган Биләрдәге «Фәнсар» фән һәм мәгариф үзәге – «Сәләт»нең тагын бер горурлыгы. «Фәнсар» – замана белән бергә атлый торган күпфункцияле комплекс.

Һәр аланда «Сәләт»кә генә хас булган мохит хөкем сөрә; милли гореф-гадәтләрне саклау, бердәмлек һәм дуслык хисе, фәнгә, белемгә омтылу, шәхес буларак үсү – «Сәләт»нең төп билгеләмәләре.

Берләшмәнең рәсми сайтында (selet.biz) күптөрле юнәлешләр (тел, тарих, интеллектуаль-иҗади, эшмәкәрлек, Worldskills, IT, КВН) буенча барлык сменалар да күрсәтелгән. Алар белән тулырак танышып чыккач, portfolio-selet.ru сайтында теркәлү үтеп, үзеңә ошаган аланга гариза калдырсаң да була. Портфолиода барлык казанышларыңны да күрсәтү кирәк.

**АЛЬБИНА КАДЫЙРОВА,**
**«Сәләт-Шәхес 2017» аланы директоры:**

– Һәр җәйге профильле сменаның үз юнәлеше, үз үзенчәлеге бар. Һәр директор командасы белән смена күңелле һәм файдалы үтсен өчен тырыша. Гариза калдырыгыз һәм үзегез килеп тикшереп карагыз! Сәләтне сүзләр белән генә аңлатып бетерерлек түгел, тоярга кирәк! Шәхсән минем өчен «Сәләт» – гадәти яшьләр оешмасы гына түгел, тормыш та, сулар һава да.

Июнь аенда башланачак беренче смена аланнары белән танышыйк.

Истанбулдагы Зәңгәр мәчетне, Париждагы Эйфель башнясын күрәсең киләме? Бәлки Италиянең иң тәмле пиццасын авыз итеп карарга телисеңдер? Үзеңне Нойшванштайн сараеның патшасы яки патшабикәсе итеп күрергә хыялланасыңмы? Бөек Кытай стенасын үлчәп карарга, дөяләрне кулга ияләштерергә уйладыңмы? Сихри сәнгать дөньясына чумып, халык мәдәниятен

өйрәнәсең киләме? Рәхим ит – «Сәләт-Тел» аланында чит телләрне өйрән!

**ТИМУР ФӘТХУЛЛОВ, «Сәләт-Тел 2017» аланы директоры:**

– Быел беренче тапкыр үземне директор буларак сынап карарга исәп. Гомумән алганда, «Сәләт-Тел»дә мин күптәннән, 2012 елда әйдаман буларак та катнашкан идем. Быелгы сменага планнар зурдан: остаханәләр исемлегенә сәхнә теле, массаж, флористика юнәлешләрен дә өстәргә ниятлим.

Әгәр инде үзеңне сүздә генә түгел, эштә дә күрсәтәсең килә икән, өстәвенә кулларың да «алтын» булса (яисә шундыйга әверелүләрен теләсәң), «Сәләт-Осталар бистәсе» аланына рәхим ит! Архитектура сәнгате, дизайн һәм 3d-модельләштерү кебек юнәлешләр дә кызыксындырса – икеләнергә җирлек юк – тизрәк «Осталар бистәсе»нә гариза калдыр!

**АЛИЯ ВӘЛИЕВА, «Сәләт-Осталар бистәсе 2017» аланы директоры:**

– Берләшмәдә мин 2007 елдан бирле. 2007-2010 елларда «Раушан» сәлкеше идем, 2012-2014 елларда шул аланның әйдаманына әйләндем. 2016 елда беренче тапкыр үземне «Яр Чаллы» һәм «Имәнкәй» аланнарында өлкән әйдаман ролендә сынап карадым. Быел инде директор вазифасын башкарып карыйсы иде. Сменага ныклап әзерләнәбез, бик кызыклы булырга охшаган. Уку-укыту программасы өстендә фикер алышабыз: ул балаларга һөнәр сайларга ярдәм итү һәм Juniour Skills эш һөнәрләре чемпионатына багышланган булачак.

Икенче смена вакытында безне «Сәләт-Самара» аланы сөендерәчәк. Лагерьның әйдаманнар командасы смена шәп узсынга кулдан килгәннең барын да эшләргә вәгъдә итә. Уку-укыту программасында төп игътибар фәнни дисциплиналарга биреләчәк: физика, математика, программалаштыру, кытай, инглиз һәм татар телләре. Танылган шәхесләр белән берлектә кызыклы темаларга остаханәләр дә үтәчәк: КВН, «Нәрсә? Кайда? Кайчан?» интеллектуаль уены, ораторлык осталыгы, дизайн, видео төшерү һәм монтаж, handmade. Спортка да игътибар җитәрлек: программа буенча футбол, волейбол, өстәл теннисы каралган. Моңсуланып утырырга вакыт булмачак! Җәй ул – үзе кечкенә бер гомер, аны кызыклы һәм мавыктыргыч вакыйгаларга бай итү үзеңнән тора!

**САБИР ГАЛИМУЛЛИН, «Сәләт-Самара» клубы рәисе:**

– Сәләттә мин 2014 елдан бирле. Шактый күп проектларда катнашып өлгердем: «Сәләт-Олимп» фән олимпиадаларына әзерләү мәктәбендә, «Фәнсар» мәктәбенең сессияләрендә һәм, әлбәттә, Биләрдә узган «Сәләт» форумында. 2016 елда Самара шәһәренең Яктылык мәктәбе базасында «Сәләт-Самара» клубы эшли башлады. Ә быелның җәендә беренче җәйге смена да узачак. Безнең өчен бу зур шатлык! Барысы да бик шәп булачагына шигем юк! Беренчедән, «Сәләт» – мөмкинлекләр иле. Һәр баланың сәләте бар, монда шул сәләтне күреп аны ачу, үстерү өчен күп көч куела. Икенчедән, «Сәләт» ул – гаилә. Өченчедән – дустанә мохит һәм позитив. Мин яратам сине, «Сәләт»!

**МӘРЬЯМ ГЫЙМАДИЕВА, Казан, 14 яшь:**

– Сәләтнең өч сменасында булдым: «Сәләт-Санак» (2015, 2016), «Сәләт-Тел» (2016), «Сәләт-Олимп» (2016). Бу җәйне дә өч аланга барырга җыенам: «Санак», «Тел» һәм «Раушан». Лагерьлар бик күп, тик алар берсе дә «Сәләт»кә җитми. «Сәләт» аланнарының үзенә күрә бер рәхәтлеге бар. Шәхсән мин түземсезлек белән җәйне, җәйге аланнарны көтәм. Чөнки биредә син кабаттан дусларың белән күрешәсең, кызыклы дәресләр тыңлыйсың, рәхәтләнеп биисең, җырлыйсың. «Сәләт»тә тагын үзеңне төрле өлкәләрдә сынап карау мөмкинлеге дә бар. Күзаллау дәрәҗәң дә үсә, яңа танышларың барлыкка килә.

**ИСЛАМ МИРГАЯЗОВ, Казан, 15 яшь:**

– «Сәләт» турында мин 2009 елда ишеттем. Шул елны ук «Сәләт-Тел»дә ял иттем. «Сәләт» мохитенә, Лаеш һавасына гашыйк булдым! 2010 елда тагын «Сәләт»кә бардым, тик шуннан соң дүрт елга якын яраткан «Звездный» базасына барырга туры килмәде. 2014 елда Биләрдә гаиләм белән ял иттем. Дүрт ел эчендә «Сәләт» әйтеп-бетергесез үзгәргән иде! Шунда үземә икенче елга «Сәләт»кә барам, дип вәгъдә бирдем! Шулай эшләдем дә: «Сәләт-Раушан 2015», «Сәләт-Раушан 2016», «Сәләт-Тел 2009», «Сәләт-Тел 2010», «Сәләт-Тел 2016». Барлыгы биш тапкыр!

Быел да шунда ук барырга ниятлим. «Сәләт-Монреаль»гә бик барасым килә! Америкага бару – күптәнге хыялым, ә «Сәләт» миңа бу мөмкинлекне бирә. Хәзер барысы да үземнән тора. «Иске Казан»га да бару теләге бар.

Дөресен генә әйткәндә, «Сәләт» минем өчен аңлатып булмаслык дөнья. Кешеләр, вакыйгалар – бүтән галәмнән шикелле хәтта! Биредәге активистлар икенче гаилә ролен үти, тәҗрибә, онытылмаслык хис-кичерешләр бирә. Бер генә сменадан соң да еламыйча кайтканым юк! «Сәләт» – мөмкинлекләр, идеяләр, иҗат мохите.

*«Сәләт» медиа үзәге*